Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авыл җирлегенең
Кама-Исмәгыйль торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре
турындагы карары

22 ноябрь 2024 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2024 елның 22 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, 2024 елның 22 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сораулар буенча: «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авыл җирлеге Кама-Исмәгыйль авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 600 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү торбаларын алмаштыру, задвижкалар урнаштыру, коелар урнаштыру)?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 435 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 225 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 225 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авыл җирлегенең Кама-Исмәгыйль авылы гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авыл җирлеге Кама-Исмәгыйль авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 600 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү торбаларын алмаштыру, задвижкалар урнаштыру, коелар урнаштыру)?» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Кама-Исмәгыйль авылы, Ленин урамы, 92а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, «Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Кама-Исмәгыйль авыл җирлеге башлыгы А.З.Шайдуллина

КАМА-ИСМАГИЛОВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ СОВЕТ
ИНН 1607002226
КПП 164401001
ОГРН 1021601628465